Л.М. Фарухшина

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР
# 1 КЛАСС

**Фортепиано сыйныфы укучылары
һәм укытучылары өчен
укыту-методик ярдәмлеге**



2025/11/29 13:37

*Л.М. Фарухшина*

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

**<u>1 КЛАСС</u>**

**Фортепиано сыйныфы укучылары һәм укытучылары өчен**
**укыту-методик ярдәмлеге**

Актаныш

2025 ел

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

## 1 КЛАСС

**Фортепиано сыйныфы укучылары һәм укытучылары өчен**

**Укыту-методик ярдәмлеге**

+0  29.12.2010 No 436 Россия Федерациясенең Федераль законы нигезендә


**Төзүче:** Ләйсән Мирзанур кызы Фарухшина

lejsanfaruchshina@gmail.com

**Ноталар бастыру һәм редакция:** Алсу Айрат кызы Баһаутдинова

minikaevaalsu@gmail.com

**Бәяләмә**

Алсу Айрат кызы Баһаутдинова редакциясендәге
Ләйсән Мирзанур кызы Фарухшинаның беренче сыйныф укучылары өчен
ярдәмлекләр җыентыгына

Җыентыкны төзегәндә илһамдыручы булып Ирина Королькованың “Крохе-музыканту” методик кулланмасы тора.

Л. М. Фарухшинаның балалар сәнгать мәктәбенең беренче сыйныф укучылары өчен җыентыгы яшь музыкантларны милли музыкаль мәдәнияткә тартуга һәм аларның сәнгати зәвыгын укытуның беренче адымнарыннан ук үстерүгә кыйммәтле укыту - методик материал булып тора.

Җыентыкка кергән әсәрләр аңлаешлы фактура, башлап җибәрүчеләр өчен уңайлы диапазон һәм тәэсирле көй белән аерылып торалар. Музыкаль грамоталылыкның нигезен дә үз эченә алуы сөендерә. Бу укучыга музыкаль әсәрләрдә төп күнекмәләрне һәм теоретик белемнәрне ныгытырга мөмкинлек бирә.

Жанр һәм эмоциональ эчтәлекнең төрлелеген билгеләп үтү аеруча мөһим: җыентыкта бию көйләре, лирик миниатюралар, уен һәм программа пьесалары тәкъдим ителгән. Мондый күптөрлелек күзаллау, музыка ишетү үсешенә һәм мөстәкыйль интерпретациягә кызыксыну формалаштыруга ярдәм итә. Милли интонация әйләнешләре һәм характерлы ритмнар укучыга татар музыкаль сөйләменең үзенчәлекләре белән танышырга булыша, техник һәм музыкаль-образлы үсеш мөмкинлеге бирә.

Җыентык төп укыту программасы кысаларында да, концерт чыгышлары һәм мәктәп чаралары өчен өстәмә репертуар сыйфатында да кулланырга мөмкин.

Гомумән алганда, ярдәмлекне яхшы уйланылган, методик яктан үлчәүле һәм сәнгати кыйммәтле дип бәяләргә мөмкин. Ул милли мәдәнияткә кызыксынуларны үстерүгә ярдәм итә һәм яшь музыкантларны татар композиторлары иҗаты белән беренче тапкыр таныштыру өчен менә дигән материал булып хезмәт итә.

*Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре,*
*Рәсәй пианист-концертмейстерлар гильдиясе әгъзасы, Фәрид Яруллин*
*исемендәге Әлмәт музыка көллиятенең “Фортепиано” бүлеге җитәкчесе –*
***Әлфия Мөнир кызы Шиһапова***


Татар халкы – җырлы халык, моңлы халык. Телдән - телгә, күңелдән -күңелгә күчеп, ул моңнар ерак гасырлардан бүгенге көннәргә килеп җиткәннәр. Телне саклап калуда да көйләрнең әһәмияте аеруча зур. Шуңа күрә, балаларга милли моңнарыбызны кечкенәдән сеңдерә алсак, милләтебезнең киләчәге нык, сәламәт һәм өметле булыр.

Елдан-ел музыка мәктәпләрендә фортепиано сәнгате белән кызыксыну республикабызда артып бара. Шунлыктан профессиональ башкару осталыгын үстерә торган татарча репертуар аерым игътибарга лаек. Бу ярдәмлекнең төп максаты – фортепиано сыйныфында укучы балаларга ноталарны тану һәм беренче алымнарны кулланырга өйрәнү булып тора.

Методик-ярдәмлекне башкаруда зур үрнәк булып, танылган пианист һәм композитор Ирина Королькованың җыентыклары торды. Шуңа да карамастан, кулланманың үзенчәлеге – үзебезнең татар телендә булуы һәм көйләрнең татар пентатоникасында язылуы.

Әлеге җыентыкта музыка иленә беренче адымнар ясаган кечкенә балалар өчен, аларның яшь мөмкинлекләренә карап, төрле аңлатмалар, күнегүләр һәм әсәрләр тәкъдим ителде.

**Ләйсән Фарухшина һәм Алсу Баһаутдинова**



Фортепианода уйнарга өйрәнү башта ноталарсыз, көйне ишетеп уйнаудан (ничек ишетәм – шулай уйныйм) һәм укытучы башкаруында (аның аңлатмалары белән) музыка әсәрләре тыңлаудан башлана. Беренче дәрестән үк баланың музыканы ишетү һәм аңлауга юнәлгән.

Беренче күнегүләр бик гади һәм табигатькә бәйләнгән.

1. **«Куяннар».** Бер клавиша аралаш 2-3 бармактан сикерәләр:




2. **«Басма».** Басма аркылы мәктәпкә барабыз. Кара клавишалардан 2-3 бармаклар белән уйнала:




3. **«Салават күпере».** До нотасын табу һәм октавалардан, һавада матур итеп “салават күперләрен” күрсәтеп уйнау. Уң кул белән уң якка, сул кул белән сул якка:



4. **«Парашютлар».** “Салават күпере”нә охшаган күнегү, ләкин монда октаваларны кара клавишалардан уйнарга кирәк:




Бармаклар йөгереклеге һәм сөйләм рәвешле бер-берсенә бәйле булганга, кечкенә күнегүләр сүзләр яки текст белән ритмик төйгәллек уйнала, җырлана.

5. **Интонацияләр.**



## *Тукран*

***Укытучы:***







## *Карга*

***Укытучы:***



# ДО нотасы






Фортепианода уйнауны өченче бармактан башлау яхшырак.

## *Тукран*




*Тук, тук, тукыран, тукылдатып утырам.*



# РЕ нотасы






## *Карга*




*Карга әйтә: "Карр-карр!*

*Мичтә бәлеш бар-бар!"*

# *Карлыгач*

***Укытучы:***







# *Кәҗә*

***Укытучы:***



# **МИ нотасы**







## ***Карлыгач***



*Кулы юк, балчык ташый*

*Тал чыбыктан өй ясый.*



## ***<u>Реприза</u> – кабатлау билгесе.***

## ***Кәҗә***





*Кәҗә кергән бакчага,*

*Кәбестәне ашарга.*

*Таяк тотып чыксалар,*

*Хәзер тора качарга.*

# Ноталарның озынлыгы





## *Яңгыр*

***Укытучы:***



# Пауза

***Пауза* – дәшмәү билгесе.**



## *Яңгыр*




*Яңгыр яу, яу, яу.*


*Сине көтә җир, җир,*

*Безгә күмәч бир, бир!*



# *Фа*


***<u>Укытучы:</u>***





# *Иң татлы тел*


***<u>Укытучы:</u>***






# <u>ФА нотасы</u>






## *Фа*




*Менә бу – нота фа.*

*Карап торма син дорфа.*

# <u>СОЛЬ нотасы</u>






## *Иң татлы тел*




*Иң матур тел – туган тел.*

*Анам сөйләп торган тел.*


# *Кояшкай*


***Укытучы:***






# <u>ЛЯ нотасы</u>






## *Кояшкай*




*Кояшкай, кояшкай,*

*Ныг(ы)рак яктырт син.*

*Җиргә нурлар сибеп,*

*Бар донья балкысын.*

## *Такмак*




*Бие-бие, Хайбулла,*

*Биегән кеше бай була.*

*Бай булмаса тук була,*

*Кайгы-моңы юк була.*

# ***Кем нинди төш күрә***

***<u>Укытучы:</u>***








## ***<u>Legato</u> – бәйләнешле уйнау.***


Legato белән уйнауны 2нче һәм 3нче бармаклардан башлау киңәш ителә.

***<u>Күнегү:</u>***



# <u>СИ нотасы</u>






## ***<u>Затакт</u> – тулы булмаган такт.***

## ***Кем нинди төш күрә***




*Төлке төшенә*

*Тавыклар керә,*

*Бүре төшенә*

*Сарыклар керә.*

*Бал корты төштә*

*Чәчәкләр күрә.*

*Ә тәмлетамак,*

*Чәк-чәкләр күрә.*

*Х. Халиков*



***Диез*** ***– нотаны ярты тонга күтәрә торган билге.***



***Бемоль*** ***– нотаны ярты тонга төшерә торган билге.***

**Күнегү**





# *Мәк*




*Безнең бакчаны матурлап,*

*Балкып утыра бер мәк.*

*Әйтерсең ул яңа тегеп,*

*Кигән ал ефәк күлмәк.*

*Р. Валиева*

# Икенче октава ДО нотасы






## *Кашкарый*

***Укытучы:***



***Озынайтылган нота*** ***–***

***Бер биеклектәге ноталар арасында лига торганда икенче нота кабатланмый, ә беренчесен дәвам итә.***



## *Сәлам бирсәң...*

***Укытучы:***



## *Кашкарый*






***Ноктaлы нота*** ***– нотаның янындагы ноктаны чутларга кирәк. Ул төп нотаның яртысын билгели.***

## *Сәлам бирсәң...*




*Сәлам бирсәң*
*Туры карап күзләренә,*
*Кояш чыга*
*Кешеләрнең йөзләренә.*

*Бигрәк тә мин*
*Сөендерәм өлкәннәрне.*
*Җенем сөйми*
*Күреп-күрми үткәннәрне.*

*Х. Халиков*

## **<u>Staccato</u> – өзек-өзек уйнау.**



# *Тизрәк кил!*




*Сикерә туп: тып, тып, тып.*

*Йөгерә туп: топ, топ, топ.*

*Йомры булгач тик тормый,*

*Машинага утырмый,*

*Җәяү чаба, топтырмый.*

# *Бака*

***<u>Укытучы:</u>***



***<u>Тенуто</u> – нотаның озынлыгын тулысынча тотып бетерергә кирәк.***



## *Туп*




## *Бака*





*Камышлы күлдә,*
*Куак төбенә,*
*Ята быгырдап,*
*Зур башлы бака.*


*Батып һәм калкып,*
*Су дулкынлатып,*
*Тынмый кычкыра:*
*“Ба-ка-ка-ка-ка”*

*Ә. Кәри*

# БАС ачкычы





## Беренче күнегү "Салават күпере".



## Икенче күнегү.




## Өченче күнегү.




## Дүртенче күнегү.



## Бишенче күнегү.




## Алтынчы күнегү.



Киләсе әсәр укучыларның фантазиясен үстерүгә юнәлдергән. Күнегүнең ахырын узеңә уйлап табарга кирәк.

# *Аю*





*Урманда аю яши –*

*Бик яратып бал ашый.*

*Кура җиләк ярата.*

*Кыш буе йоклап ята.*

# *Фил*



*Зоопаркта фил күрдем.*

*Нинди зур икән белдем.*

*Ягымлы карады,*

*Борынын да болгады.*


# *Зилем*

*Татар халык жұыры*




# *Яз җитә*

*Җ. Файзи*



# *Умырзаялар*




*Карны тишеп чыккан алар,*

*Нинди чаялар.*

*Чәчәк аткан, чәчәк аткан,*

*Умырзаялар.*

*Шушы чәчәкләрдә кебек,*

*Җирнең бар яме.*

*Язның әле башы гына,*

*Алда дәвамы.*

*Г. Мөхәммәтшин*



## <u>*Фермата*</u> *– нота яки пауза озыная.*

## *Җитәкләшеп җил белән*




## *Сандугач*



# *Җиңел вариацияләр*

*Т.х.к. “Ату кырлары” темасына*






# *Атта барам*





*Л.М. Фарухшина*

# БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР

**<u>1 КЛАСС</u>**

**Фортепиано сыйныфы укучылары һәм укытучылары өчен укыту-методик ярдәмлеге**

Актаныш басмаханәсе (ИП Вазиев И.Х.)
423740, ТР, Актаныш авылы,
Ленин проспекты, 4 нче йорт.